**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 22 декабря 1992 года № 1708-XII «О Конституционном суде Республики Татарстан» (в редакции Закона Республики Татарстан от 30 октября 1998 года № 1840) (Ведомости Верховного Совета Татарстана, 1992, № 11 – 12; Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I часть), № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008, № 3; 2009, № 12 (I часть); 2015, № 11 (I часть); 2016, № 3; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 83 (часть I) следующие изменения:

1) преамбулу после слов «в соответствии с» дополнить словами «Конституцией Республики Татарстан и»;

2) в части девятой статьи 3 слова «государственной власти Республики Татарстан» исключить;

3) в статье 6 слова «предприятий, учреждений,» исключить;

4) в статье 7:
а) в части второй:
абзац первый после слов «за счет» дополнить словом «средств»;
в абзаце втором слово «статьей» заменить словом «строкой»;
б) в части четвертой слова «настоящим Законом» заменить словами «федеральным законодательством, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан»;

5) пункт 1 части первой статьи 8 изложить в следующей редакции:

«1) не моложе 25 лет, имеющий высшее юридическое образование по специальности «Юриспруденция» или высшее образование по направлению подготовки «Юриспруденция» квалификации (степени) «магистр» при наличии диплома бакалавра по направлению подготовки «Юриспруденция», а также стаж работы в области юриспруденции не менее пяти лет;»;

6) часть вторую статьи 9 изложить в следующей редакции:

«2. Вопрос об избрании на должность судьи Конституционного суда Республики Татарстан рассматривается на заседании Государственного Совета Республики Татарстан не позднее одного месяца со дня получения соответствующих представлений Президента Республики Татарстан и Председателя Государственного Совета Республики Татарстан.»;

7) в части первой статьи 10 слово «сессии» заменить словом «заседании»;

8) статью 11 изложить в следующей редакции:

«Статья 11. **Ограничения, обязанности и запреты для судей Конституционного суда Республики Татарстан**

На судей Конституционного суда Республики Татарстан распространяются ограничения, обязанности и запреты, установленные в отношении судей Законом Российской Федерации от 26 июня 1992 года № 3132-1 «О статусе судей в Российской Федерации», другими федеральными законами и законами Республики Татарстан.»;

9) в статье 17:

а) наименование дополнить словами «Республики Татарстан»;

б) слова «органа государственной власти Республики Татарстан» заменить словами «государственного органа Республики Татарстан»;

10) в статье 18:

а) в части первой слова «и его имущество» заменить словами «, члены его семьи и их имущество»;

б) в части второй слово «ему» заменить словом «им»;

11) в части третьей статьи 19 слова «Верховного суда» заменить словами «Верховного Суда»;

12) статью 20 изложить в следующей редакции:

«Статья 20. **Приостановление полномочий судьи Конституционного суда Республики Татарстан и отставки судьи Конституционного суда Республики Татарстан**

1. Полномочия судьи Конституционного суда Республики Татарстан и отставка судьи Конституционного суда Республики Татарстан приостанавливаются решением Квалификационной коллегии судей Республики Татарстан при наличии одного из следующих оснований:

1) признание судьи безвестно отсутствующим решением суда, вступившим в законную силу;

2) возбуждение уголовного дела в отношении судьи либо привлечение его в качестве обвиняемого по другому уголовному делу;

3) участие судьи в качестве кандидата в выборах Президента Российской Федерации, депутатов Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации, депутатов Государственного Совета Республики Татарстан, в законодательный (представительный) орган государственной власти иного субъекта Российской Федерации, представительный орган муниципального образования, а также главы муниципального образования или выборного должностного лица местного самоуправления.

2. Приостановление полномочий судьи Конституционного суда Республики Татарстан и отставки судьи Конституционного суда Республики Татарстан, за исключением случая, когда ему в качестве меры пресечения избрано заключение под стражу, не влечет за собой прекращение выплаты судье, а если он признан безвестно отсутствующим – его семье ежемесячного денежного вознаграждения или уменьшение его размера. Приостановление полномочий судьи Конституционного суда Республики Татарстан и отставки судьи Конституционного суда Республики Татарстан, за исключением случая избрания ему в качестве меры пресечения заключения под стражу, не влечет за собой снижение уровня иных видов материального и социального обеспечения судьи и членов его семьи, а также не лишает судью гарантий неприкосновенности, установленных законодательством.

3. Решение о возобновлении полномочий судьи Конституционного суда Республики Татарстан или отставки судьи Конституционного суда Республики Татарстан принимает Квалификационная коллегия судей Республики Татарстан.»;

13) в статье 21:

а) в части первой:

дополнить пунктами $6^1$ и $6^2$ следующего содержания:

«$6^1$) избрание судьи Президентом Российской Федерации, депутатом Государственной Думы Федерального Собрания Российской Федерации, Государственного Совета Республики Татарстан, законодательного (представительного) органа государственной власти иного субъекта Российской Федерации, представительного органа муниципального образования, а также главой муниципального образования или выборным должностным лицом местного самоуправления;

$6^2$) нарушение судьей, его супругой (супругом) и несовершеннолетними детьми запрета открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами. Понятие «иностранные финансовые инструменты» используется в

настоящем Законе в значении, определенном Федеральным законом от 7 мая 2013 года № 79-ФЗ «О запрете отдельным категориям лиц открывать и иметь счета (вклады), хранить наличные денежные средства и ценности в иностранных банках, расположенных за пределами территории Российской Федерации, владеть и (или) пользоваться иностранными финансовыми инструментами»;»;

б) в части второй слова «могут быть прекращены» заменить словом «прекращаются»;

в) в части третьей слова «Квалификационной коллегии судей Республики Татарстан» исключить;

14) часть третью статьи 22 изложить в следующей редакции:

«3. На пребывающего в отставке судью Конституционного суда Республики Татарстан распространяются также иные положения статуса судьи, пребывающего в отставке, установленные законодательством.»;

15) часть вторую статьи 24 изложить в следующей редакции:

«2. В заседании Конституционного суда Республики Татарстан могут участвовать Президент Республики Татарстан, Председатель Государственного Совета Республики Татарстан, Премьер-министр Республики Татарстан, Председатель Верховного Суда Республики Татарстан, Председатель Арбитражного суда Республики Татарстан, Прокурор Республики Татарстан, Уполномоченный по правам человека в Республике Татарстан либо их представители, которые вправе излагать позицию по рассматриваемым вопросам.»;

16) в статье 25:

а) пункт 4 части первой после слов «государственными органами» дополнить словами «, органами местного самоуправления»;

б) часть вторую признать утратившей силу;

17) часть первую статьи 30 после слова «только» дополнить словами «Конституцией Российской Федерации,»;

18) часть первую статьи 33 после слова «экспертов,» дополнить словами «консультации специалистов,»;

19) часть вторую статьи 35 признать утратившей силу;

20) статьи 36 и 37 признать утратившими силу;

21) в пункте 6 части второй статьи 40 слово «название» заменить словом «наименование»;

22) в статье 41:

а) часть вторую после слова «экспертов,» дополнить словом «специалистов,»;

б) в части третьей слова «органами, учреждениями, организациями с копиями в количестве шести экземпляров, гражданами – с копиями в количестве трех экземпляров» заменить словами «с одной копией»;

23) статью 43 изложить в следующей редакции:

«Статья 43. **Рассмотрение обращений аппаратом Конституционного суда Республики Татарстан**

1. Обращения, поступающие в Конституционный суд Республики Татарстан, подлежат обязательной регистрации аппаратом Конституционного суда Республики Татарстан.

2. Аппарат Конституционного суда Республики Татарстан уведомляет заявителя о несоответствии его обращения требованиям настоящего Закона в случаях, если обращение:

1) явно не подведомственно Конституционному суду Республики Татарстан;

2) по форме не отвечает требованиям настоящего Закона;

3) исходит от ненадлежащего органа или лица;

4) не оплачено государственной пошлиной, если иное не установлено федеральным законодательством.

3. Заявитель в случаях, указанных в части второй настоящей статьи, вправе потребовать принятия Конституционным судом Республики Татарстан решения о несоответствии его обращения требованиям настоящего Закона.

4. После устранения недостатков, указанных в пунктах 2 и 4 части второй настоящей статьи, заявитель вправе вновь направить обращение в Конституционный суд Республики Татарстан.

5. В случае, если обращение явно не подведомственно Конституционному суду Республики Татарстан, аппарат Конституционного суда Республики Татарстан может направить его в органы или организации, в компетенцию которых входит решение поставленных в нем вопросов.»;

24) в части второй статьи 46 слова «может быть прекращено» заменить словами «по данному делу прекращается»;

25) статью 50 изложить в следующей редакции:

«Статья 50. **Назначение дел к слушанию**

1. Решение о назначении дел к слушанию в заседании Конституционного суда Республики Татарстан принимается Конституционным судом Республики Татарстан не позднее чем через месяц после принятия обращений к рассмотрению. В решении указывается очередность слушания дел.

2. Рассмотрение каждого дела образует предмет особого заседания. Конституционный суд Республики Татарстан может соединить в одном производстве дела по обращениям, касающимся одного и того же предмета.»;

26) часть третью статьи 52 изложить в следующей редакции:

«3. Расходы, связанные с выполнением государственными органами, органами местного самоуправления и организациями требований Конституционного суда Республики Татарстан, несут эти органы и организации.»;

27) статью 53 после слова «эксперты,» дополнить словами «специалисты и»;

28) дополнить статьей 55[1] следующего содержания:
«Статья 55[1]. **Протоколирование**

В заседании Конституционного суда Республики Татарстан ведется протокол, требования к которому устанавливаются Регламентом Конституционного суда Республики Татарстан.»;

29) в статье 56:
а) наименование после слова «судьи» дополнить словами «Конституционного суда Республики Татарстан»;
б) пункт 3 части первой изложить в следующей редакции:
«3) судья публично высказал свое мнение по вопросу, который является предметом рассмотрения в Конституционном суде Республики Татарстан, до принятия по нему решения Конституционного суда Республики Татарстан.»;

30) дополнить статьей 58[1] следующего содержания:
«Статья 58[1]. **Отложение заседания Конституционного суда Республики Татарстан**

Рассмотрение дела может быть отложено в случае, если Конституционный суд Республики Татарстан найдет вопрос недостаточно подготовленным, нуждающимся в дополнительном изучении, которое невозможно произвести в том же заседании вследствие неявки стороны, эксперта или специалиста, явка которых была признана обязательной, а также непредставления необходимых материалов. В этом случае Конституционный суд Республики Татарстан назначает дату, на которую переносится заседание. Заседание по делу, рассмотрение которого было отложено, начинается сначала или с момента, на котором оно было отложено.»;

31) в статье 59:
а) часть вторую изложить в следующей редакции:
«2. Стороны и их представители не вправе использовать свои выступления в Конституционном суде Республики Татарстан для политических заявлений и деклараций и не должны допускать оскорбительных высказываний в адрес государственных органов, органов местного самоуправления, организаций, общественных объединений, участников процесса, должностных лиц и граждан.»;
б) дополнить частью третьей следующего содержания:
«3. Объяснение стороны выслушивается Конституционным судом Республики Татарстан в полном объеме. После объяснения стороны ей могут быть заданы

вопросы судьями Конституционного суда Республики Татарстан и другой стороной, а с разрешения Конституционного суда Республики Татарстан также экспертами.»;

32) в части второй статьи 60 слова «о юридической ответственности» заменить словами «об ответственности»;

33) дополнить статьей $60^1$ следующего содержания:
«Статья $60^1$. **Консультация специалиста**

1. Конституционный суд Республики Татарстан по собственной инициативе либо по ходатайству стороны в конституционном судопроизводстве или ее представителя может привлечь специалиста для получения консультаций при исследовании и рассмотрении материалов дела.

2. Лицо, вызванное в качестве специалиста, обязано явиться на заседание Конституционного суда Республики Татарстан, отвечать на поставленные судьями Конституционного суда Республики Татарстан и сторонами вопросы, давать в устной или письменной форме консультации и пояснения, исходя из своих профессиональных знаний.

3. Консультация специалиста, данная в письменной форме, оглашается в судебном заседании и приобщается к делу. Консультации и пояснения специалиста, данные в устной форме, заносятся в протокол судебного заседания.»;

34) дополнить статьей $62^1$ следующего содержания:
«Статья $62^1$. **Возобновление судебного исследования**

1. Если после заключительных выступлений сторон Конституционный суд Республики Татарстан признает необходимым выяснить дополнительные обстоятельства, имеющие существенное значение для разрешения дела, или исследовать новые доказательства, он выносит решение о возобновлении судебного исследования.

2. По окончании дополнительного исследования стороны имеют право на повторные заключительные выступления, но лишь в связи с новыми обстоятельствами и доказательствами.»;

35) наименование статьи 65 после слова «судей» дополнить словами «Конституционного суда Республики Татарстан»;

36) наименование статьи 70 дополнить словами «Конституционного суда Республики Татарстан»;

37) статью 71 изложить в следующей редакции:
«Статья 71. **Провозглашение решения**

1. Решение Конституционного суда Республики Татарстан провозглашается в полном объеме в открытом заседании Конституционного суда Республики Татарстан немедленно после его подписания.

2. Постановления и заключения Конституционного суда Республики Татарстан не позднее чем в двухнедельный срок со дня их подписания направляются:

1) судьям Конституционного суда Республики Татарстан;

2) сторонам;

3) Президенту Республики Татарстан, Государственному Советнику Республики Татарстан, в Государственный Совет Республики Татарстан и Кабинет Министров Республики Татарстан;

4) в Верховный Суд Республики Татарстан, Арбитражный суд Республики Татарстан, Прокурору Республики Татарстан, Уполномоченному по правам человека в Республике Татарстан.

3. Решения Конституционного суда Республики Татарстан могут быть также направлены другим государственным органам, органам местного самоуправления, организациям, общественным объединениям, должностным лицам и гражданам.»;

38) статью 80 признать утратившей силу;

39) в части второй статьи 84 слова «основанием отмены» заменить словами «основанием для отмены»;

40) в пункте 5 статьи 87 слово «высшими» исключить;

41) в части второй статьи 88 слова «, то есть не может быть ратифицировано, утверждено и не может вступить в силу для Республики Татарстан иным образом» исключить;

42) в статье 90:

а) в пункте 1 слово «действующим» исключить;

б) в пункте 5 слова «органам государственной власти» заменить словами «государственным органам, органам местного самоуправления»;

43) в статье 94 слова «представительных, исполнительных и судебных органов власти» заменить словами «государственных органов», слова «предприятий, учреждений,» исключить;

44) в статье 109:

а) часть вторую после слов «государственных органов» дополнить словами «, органов местного самоуправления»;

б) в части четвертой слова «государственной службы» заменить словами «государственной гражданской службы», слова «государственной службе» заменить словами «государственной гражданской службе», слова «нормативными актами» заменить словами «нормативными правовыми актами»;

в) часть пятую признать утратившей силу.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
17 июля 2019 года
№ 59-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 12 (I өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Әлеге Закон» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Конституциясе һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 3 статьяның тугызынчы өлешендә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең» сүзләрен төшереп калдырырга, «органнары» сүзен «органнар» сүзенә алмаштырырга;

3) 6 статьяда «предприятиеләр, учреждениеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 7 статьяда:
а) икенче өлештә:
беренче абзацта «бюджеты» сүзеннән соң «акчалары» сүзен өстәргә;
икенче абзацта «статья» сүзен «юл» сүзенә алмаштырырга;
б) дүртенче өлештә «әлеге Законда» сүзләрен «федераль законнарда, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында» сүзләренә алмаштырырга;

5) 8 статьяның беренче өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 25 яшьтән дә яшьрәк булмаган, «Юриспруденция» белгечлеге буенча югары юридик белеме яисә «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча бакалавр дипломы булганда «магистр» квалификацияле (дәрәҗәле) «Юриспруденция» әзерлек юнәлеше буенча югары белеме булган, шулай ук юриспруденция өлкәсендә эш стажы кимендә биш ел булган;»;

6) 9 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфасына сайлау мәсьәләсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең тиешле тәкъдимнәре алынган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча карала.»;

7) 10 статьяның беренче өлешендә «сессиясендә» сүзен «утырышында» сүзенә алмаштырырга;

8) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары өчен чикләүләр, бурычлар һәм тыюлар**

Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына «Россия Федерациясендә судьялар статусы турында» 1992 елның 26 июнендәге 3132-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, башка федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән судьяларга карата билгеләнгән чикләүләр, бурычлар һәм тыюлар кагыла.»;

9) 17 статьяда:

а) исемендә «судьясының» сүзеннән соң «Татарстан Республикасы» сүзләрен өстәргә;

б) «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең теләсә кайсы органы» сүзләрен «Татарстан Республикасының теләсә кайсы дәүләт органы» сүзләренә алмаштырырга;

10) 18 статьяда:

а) беренче өлештә «һәм аның мөлкәте» сүзләрен «, аның гаилә әгъзалары һәм аларның мөлкәте» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче өлештә «аның» сүзен «аларның» сүзенә алмаштырырга;

11) 19 статьяның өченче өлешендә «Югары суды» сүзләрен «Югары Суды» сүзләренә алмаштырырга;

12) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкасын туктатып тору**

1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләре һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкасы Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе карары белән түбәндәге нигезләрнең берсе булганда туктатып торыла:

1) судьяны законлы көченә кергән суд карары белән хәбәрсез югалган дип таныганда;

2) судьяга карата җинаять эше кузгатылганда йә аны башка җинаять эше буенча гаепләнүче буларак җавапка тартканда;

3) судья Россия Федерациясе Президентын, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына, шулай ук муниципаль берәмлек башлыгын яисә җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын сайлауларда кандидат буларак катнашканда.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкасын туктатып тору, аны сак астына алу кисәтү чарасы буларак сайланган очрактан тыш, судьяга түләүне туктатуга китерми, әгәр ул хәбәрсез югалган дип танылса, – аның гаиләсенә айлык акчалата түләүне туктатуга яисә аның күләмен киметүгә китерми. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен һәм Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкасын туктатып тору, аны сак астына алу кисәтү чарасы буларак сайланган очрактан тыш, судьяны һәм аның гаилә әгъзаларын матди һәм социаль тәэмин итүнең башка төрләре дәрәҗәсен киметүгә китерми, шулай ук судьяны законнарда билгеләнгән кагылгысызлык гарантияләреннән мәхрүм итми.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен яисә Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы отставкасын торгызу турында карарны Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе кабул итә.»;

13) 21 статьяда:

а) беренче өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ һәм $6^2$ пунктлар өстәргә:

«$6^1$) судья Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, шулай ук муниципаль берәмлек башлыгы яисә җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты итеп сайланганда;

$6^2$) судья, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар

(кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыюны бозганда. Әлеге Законда «чит ил финанс инструментлары» төшенчәсе «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла;»;

б) икенче өлештә «туктатылырга мөмкин» сүзләрен «туктатыла» сүзенә алмаштырырга;

в) өченче өлештә «Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 22 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Конституция судының отставкадагы судьясына шулай ук отставкадагы судья статусының законнарда билгеләнгән башка нигезләмәләре дә кагыла.»;

15) 24 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Премьер-министры, Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисе, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе, Татарстан Республикасы Прокуроры, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил яисә аларның вәкилләре катнаша ала, алар карала торган мәсьәләләр буенча үз позицияләрен белдерергә хокуклы.»;

16) 25 статьяда:

а) беренче өлешнең 4 пунктында «дәүләт органнары» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

17) 30 статьяның беренче өлешендә «бары тик» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе Конституциясенә,» сүзләрен өстәргә;

18) 33 статьяның беренче өлешендә «күрсәтүләрен» сүзеннән соң «, белгечләрнең консультацияләрен» сүзләрен өстәргә;

19) 35 статьяның икенче өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

20) 36 һәм 37 статьяларны үз көчен югалткан дип танырга;

21) 40 статьяның икенче өлешендәге 6 пунктында татарча текст үзгәрешсез кала;

22) 41 статьяда:

а) икенче өлештә «экспертлар» сүзеннән соң «, белгечләр» сүзен өстәргә;

б) өченче өлештә «органнар, учреждениеләр, оешмалар тарафыннан күчермәләре белән бергә алты нөсхәдә бирелә, гражданнар тарафыннан күчермәләре белән бергә өч нөсхәдә бирелә» сүзләрен «бер нөсхәдәге күчермәсе белән бирелә» сүзләренә алмаштырырга;

23) 43 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«43 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына килә торган мөрәҗәгатьләр Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты тарафыннан һичшиксез теркәлергә тиеш.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты мөрәҗәгать итүчегә аның мөрәҗәгатенең әлеге Закон таләпләренә туры килмәве турында хәбәр итә, әгәр мөрәҗәгать:

1) Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына ачыктан-ачык туры килмәсә;

2) рәвеше буенча әлеге Закон таләпләренә туры килмәсә;

3) тиешсез органнан яисә заттан бирелгән булса;

4) федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, аның өчен дәүләт пошлинасы түләнмәсә.

3. Әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән очракларда мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан мөрәҗәгатенең әлеге Закон таләпләренә туры килмәве турында карар кабул итүне таләп итәргә хокуклы.

4. Әлеге статьяның икенче өлешендәге 2 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән җитешсезлекләр бетерелгәннән соң, мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгатен Татарстан Республикасы Конституция судына яңадан җибәрергә хокуклы.

5. Әгәр мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына ачыктан-ачык туры килмәсә, Татарстан Республикасы Конституция суды аппараты аны шундагы мәсьәләләрне хәл итү компетенцияләренә керә торган органнарга яисә оешмаларга җибәрергә мөмкин.»;

24) 46 статьяның икенче өлешендә «туктатып торылырга мөмкин» сүзләрен «буенча башкару туктатыла» сүзләренә алмаштырырга;

25) 50 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«50 статья. **Эшләрне тыңлауга билгеләү**

1. Эшләрне Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында тыңлауга билгеләү турында карар мөрәҗәгатьләрне карауга кабул иткәннән соң бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан кабул ителә. Карарда эшләрне тыңлауның чираты күрсәтелә.

2. Һәр эшне карау аерым утырыш предметын тәшкил итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бер үк предметка кагылышлы мөрәҗәгатьләр буенча эшләрне бер башкаруга берләштерергә мөмкин.»;

26) 52 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның Татарстан Республикасы Конституция суды таләпләрен үтәүгә бәйле чыгымнары шушы органнар һәм оешмалар исәбеннән тотыла.»;

27) 53 статьяда «экспертлар,» сүзеннән соң «белгечләр һәм» сүзләрен өстәргә;

28) түбәндәге эчтәлекле 55[1] статья өстәргә:

«55[1] статья. **Беркетмәләштерү**

Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында беркетмә алып барыла, аңа карата таләпләр Татарстан Республикасы Конституция суды Регламенты белән билгеләнә.»;

29) 56 статьяда:

а) исемендә «Судьяны» сүзен «Татарстан Республикасы Конституция суды судьясын» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) судья Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булган мәсьәлә буенча үз фикерен Татарстан Республикасы Конституция суды аның буенча карар кабул иткәнче халыкка ачык белдерсә.»;

30) түбәндәге эчтәлекле 58[1] статья өстәргә:

«58[1] статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды утырышын кичектерү**

Әгәр Татарстан Республикасы Конституция суды мәсьәлә җитәрлек әзерләнмәгән, килүләре мәҗбүри дип саналган як, эксперт яисә белгеч килми калу, шулай ук тиешле материаллар бирелеп бетмәү аркасында шул ук утырышта мөмкин булмаган өстәмә өйрәнүгә мохтаҗ дип санаса, эшне карау кичектерелергә мөмкин. Бу очракта Татарстан Республикасы Конституция суды утырыш күчерелә торган көнне билгели. Каралуы кичектерелгән эш буенча утырыш башыннан ук яисә кичектерелгән мизгеленнән башланып китә.»;

31) 59 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Конституция судында яклар һәм аларның вәкилләре үз чыгышларын сәяси белдерүләр һәм декларацияләр өчен файдаланмаска һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, процесста катнашучылар, вазыйфаи затлар һәм гражданнар адресына кимсетү сүзләре әйтмәскә тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«3. Якның аңлатмасы Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан тулысынча тыңлана. Якның аңлатмасыннан соң аңа Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары һәм икенче як, ә Татарстан Республикасы Конституция суды рөхсәте белән экспертлар да сораулар бирергә мөмкин.»;

32) 60 статьяның икенче өлешендә «юридик җаваплылыгы» сүзләрен «җаваплылык» сүзенә алмаштырырга;

33) түбәндәге эчтәлекле $60^1$ статья өстәргә:

«$60^1$ статья. **Белгеч консультациясе**

1. Татарстан Республикасы Конституция суды эш материалларын тикшергәндә һәм караганда үз инициативасы буенча яисә конституциячел суд башкаруындагы якның яки аның вәкиле үтенечнамәсе буенча консультацияләр алу өчен белгеч җәлеп итәргә мөмкин.
2. Белгеч сыйфатында чакырылган зат Татарстан Республикасы Конституция суды утырышына килергә, Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары һәм яклар тарафыннан куелган сорауларга җавап бирергә, үз һөнәри белеменнән чыгып, телдән яисә язмача консультацияләр һәм аңлатмалар бирергә тиеш.
3. Белгечнең язма рәвештә бирелгән консультациясе суд утырышында игълан ителә һәм эшкә теркәлә. Белгечнең телдән бирелгән консультацияләре һәм аңлатмалары суд утырышы беркетмәсенә кертелә.»;

34) түбәндәге эчтәлекле $62^1$ статья өстәргә:

«$62^1$ статья. **Суд тикшерүен яңадан башлау**

1. Әгәр якларның йомгаклау чыгышларыннан соң Татарстан Республикасы Конституция суды эшне хәл итү өчен зур әһәмияткә ия булган өстәмә шартларны ачыкларга яки яңа дәлилләрне тикшерергә кирәк дип таныса, ул суд тикшерүен яңадан башлау турында карар чыгара.
2. Өстәмә тикшерү тәмамлангач, яклар кабат йомгаклау чыгышларына хокуклы, ләкин бары тик яңа шартлар һәм дәлилләр белән бәйле рәвештә генә.»;

35) 65 статьяның исемендә «судьялар» сүзен «Татарстан Республикасы Конституция суды судьялары» сүзләренә алмаштырырга;

36) 70 статьяның исемендә «Судьяларның» сүзен «Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларының» сүзләренә алмаштырырга;

37) 71 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«71 статья. **Карарны игълан итү**

1. Татарстан Республикасы Конституция суды карары имзаланганнан соң кичекмәстән Татарстан Республикасы Конституция судының ачык утырышында тулысынча игълан ителә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары һәм бәяләмәләре имзаланганнан соң ике атнадан да соңга калмыйча түбәндәгеләргә җибәрелә:

1) Татарстан Республикасы Конституция суды судьяларына;

2) якларга;

3) Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына;

4) Татарстан Республикасы Югары Судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә.

3. Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары шулай ук башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, иҗтимагый берләшмәләргә, вазыйфаи затларга һәм гражданнарга җибәрелергә мөмкин.»;

38) 80 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

39) 84 статьяның икенче өлешендә «юкка чыгаруга сәбәп» сүзләрен «юкка чыгару өчен нигез» сүзләренә алмаштырырга;

40) 87 статьяның 5 пунктында «югары» сүзен төшереп калдырырга;

41) 88 статьяның икенче өлешендә «, ягъни ратификацияләнә, раслана һәм Татарстан Республикасы өчен башкача үз көченә керә алмый» сүзләрен төшереп калдырырга;

42) 90 статьяда:

а) 1 пунктта «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

б) 5 пунктта «дәүләт хакимияте органнарының» сүзләрен «дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

43) 94 статьяда «хакимиятнең барлык вәкиллекле, башкарма һәм суд органнары» сүзләрен «барлык дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга, «предприятиеләр, учреждениеләр,» сүзләрен төшереп калдырырга;

44) 109 статьяда:

а) икенче өлештә «дәүләт органнарының» сүзләреннән соң «, җирле үзидарә органнарының» сүзләрен өстәргә;

б) дүртенче өлештә «дәүләт хезмәтен» сүзләрен «дәүләт граждан хезмәтен» сүзләренә, «Дәүләт хезмәте» сүзләрен «Дәүләт граждан хезмәте» сүзләренә, «норматив актлар» сүзләрен «норматив хокукый актлар» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 17 июль
№ 59-ТРЗ